**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 17 октябрь | № 749

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 февраль, 128 нче, 2013 ел, 7 ноябрь, 860 нчы, 2015 ел, 26 август, 623 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.17 пунктта:

2 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктчаның икенче абзацында «товар китерүләргә заказлар урнаштыру» сүзләрен «сатып алулар» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчаның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.19 пунктта:

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

бишенче абзацта «товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыруга» сүзләрен «товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуга» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.22. Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт программалары һәм проектларының дәүләт заказчысы функцияләрен гамәлгә ашыру, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт ихтыяҗлары һәм Министрлык ихтыяҗлары өчен

товарлар сатып алуны, хезмәтләр күрсәтүне, эшләр башкаруны оештыру, фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструктор һәм технологик эшләрне кертеп.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.42 – 3.3.47 пунктлар өстәргә:

«3.3.42. Үз компетенциясе кысаларында экстремистик эшчәнлеккә һәм террорчылыкка каршы торуда катнашу.

3.3.43. Татарстан Республикасы территориясендә кылынган террорчылык акты нәтиҗәсендә зыян күргән затларга һәм аны булдырмауда катнашучыларга медицина ярдәме күрсәтү буенча эшне оештыру.

3.3.44. Террорчылыкка каршы тору буенча чараларны гамәлгә ашыруда укулар үткәрүдә катнашу.

3.3.45. Министрлыкка беркетелгән объектларны (территорияләрне) террорчылыктан саклауны тәэмин итү.

3.3.46. Кадрлар сәясәтен тормышка ашыру, шул исәптән башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем профессияләре һәм белгечлекләре буенча квалификацияле эшчеләр һәм белгечләр әзерләүдә сәламәтлек саклау өлкәсе ихтыяҗы фаразын формалаштыру.

3.3.47. Сәламәтлек саклау объектларының, Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә тормышка ашырыла торган масштаблы инвестиция проектларының Татарстан Республикасы Җир кодексның 33.3 статьясында күрсәтелгән критерияләргә, мондый критерияләрнең Татарстан Республикасы президенты билгели торган сыйфат һәм (яки) сан күрсәткечләренә туры килүе турында юридик затлар документларын карап тикшерү һәм бәяләмә проектларын килештерү.»;

3.3.9, 3.3.11, 3.3.12, 3.3.26, 3.3.27, 3.3.31, 3.3.32 һәм 3.3.33 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.4 пункт өстәргә:

«5.4. Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү министр боерыгы белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\749.docx